КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 16 июль г.Казань № 518

2025 – 2026 елларда футбол буенча Россия чемпионатының футбол матчын үткәрү көнендә алкогольле продукцияне ваклап сатуны чикләү турында

«Этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм әйләнештә йөртүне дәүләт тарафыннан җайга салу турында һәм алкогольле продукцияне куллануны (эчүне) чикләү хакында» 1995 елның 22 ноябрендәге 171-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Казан шәһәрендә Россия Премьер-лигасы командалары «Рубин» (Казан шәһәре) – «Зенит» (Санкт-Петербург шәһәре) арасында 2025 – 2026 елларда футбол буенча Россия чемпионатының футбол матчын үткәргәндә иминлекне тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2025 елның 27 июлендә әлеге карарның кушымтасында күрсәтелгән территорияләр чикләрендә, шулай ук Казан шәһәренең Астрономия, Бауман, Кави Нәҗми, Муса Җәлил, Профсоюз, Университет, Чернышевский урамнарындагы сәүдә объектларында алкогольле продукцияне ваклап сату (җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сатудан тыш) рөхсәт ителми дип билгеләргә.

2. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты белән берлектә, халыкка кертелә торган чикләү турында мәгълүмат бирү эшен оештырырга.


3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүне, әйләнештә йөртүне һәм аларның сыйфатын дәүләт тикшерүендә тотуны тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясенә һәм килешү буенча Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына йөкләргә.

4. Бу карар рәсми басылып чыккан көннән 10 көн узгач үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 ел, 16 июль, 518 нче карарына кушымта

Казан шәһәрендә алкогольле продукцияне ваклап сату рөхсәт ителми торган территорияләр чикләре




Урамнарның чикләре: С.Хәким урамыннан алып Чистай урамына кадәр Әмирхан проспекты буенча, Чистай урамы буенча Адоратский урамына кадәр, Адоратский урамы буенча Лаврентьев урамына кадәр, ишегалды территорияләре буйлап Лаврентьев урамы буенча Гаврилов урамы, 10 нчы йортка кадәр, алга таба 3 нче транспорт дамбасының әйләнеп уза торган күпер чиге буенча («Мегастрой» кибетен кертеп) Троицкий урманы урамына кадәр, Троицкий урманы урамы буенча, алга таба Казансу елгасының су акваториясе кыры буйлап Әмирхан проспектына кадәр.